Балалар өчен Изге Язма
тәкъдим итә



# Оҗмах, гүзәл Аллаһы йорты

Автор: Edward Hughes
Рәсемнәр: Lazarus
Alastair Paterson
Кемнәр өчен: Sarah S.
Тәрҗемә ителде: www.christian-translation.com
Гамәлгә ашырылды: Bible for Children
www.M1914.org

BFC
PO Box 3
Winnipeg, MB R3C 2G1
Canada

©2020 Bible for Children, Inc.
Лицензия: Сезнең бу хикәят текстын, сату хокукыннан башка гына, күчермә итеп яки бастырып алу хокукыгыз бар.



Җир йөзендә яшәгән вакытта Гайсә шәкертләренә Күкләр Патшалыгы турында сөйли. Ул аны “Минем Атам йорты” дип атый һәм анда бик күп тораклар булуы турында әйтә. Торак – бик зур, матур йорт. Күкләр Патшалыгы Җир йөзендәге теләсә кайсы йорттан зуррак һәм гүзәлрәк, дип әйтә.



Гайсә әйтә: “Мин сезгә урын әзерләргә барам. Сезнең өчен урын әзерләп бетергәч, кайтырмын һәм сезне Үз янына алырмын”, - ди. Үлеп терелгәннән соң, Гайсә, чыннан да, Күккә алына. Гайсә Мәсих шәкертләренең күз алдында Күккә аша һәм болытлар арасында күз уңыннан юк була.



3

Шул вакыттан бирле христианнар Гайсәнең кайтачагы турындагы вәгъдәсен хәтерләп яши. Гайсә беркем дә көтмәгәндә, кисәк кайтачагы турында әйтә. Ләкин ул кайтканчыга кадәр үлгән христианнар белән ни булыр? Изге Язмада, алар шундук Гайсә янына китә, диелә. Җанның тәннән аерылуы – Аллаһы Тәгалә янында булу, дигән сүз.




4

Изге Язманың соңгы – Ачылыш китабында Күкләр Паташалыгының никадәр матур булуы турында әйтелә. Иң гаҗәпләндергәне, Күкләр Патшалыгы – Аллаһы йорты, үзенә бер төрле аерым йорт булып тора. Аллаһы – һәркайда, ләкин Аның тәхете Күкләр Патшалыгында урнашкан.



5

Фәрештәләр һәм Күкләр Патшалыгындагы башка ияләр Аллаһыга сәҗдә кыла. Үлеп, Күкләргә ашкан Аллаһы бәндәләре дә шулай эшли. Алар Аллаһыга шөкрана итеп, үзенчәлекле мәдхия җырларын җырлыйлар.



6

Аларның бер җырыннан: “Син язма төргәген алырга, аның мөһерләрен кубарырга лаеклы, чөнки корбан итеп суелдың, Үзеңнең каның белән һәр кабиләдән һәм телдән, һәр халыктан һәм милләттән Аллаһы өчен кешеләрне йолып алдың”. (Ачылыш, 5:9)



7

Изге Язманың иң соңгы битләрендә Күкләр Патшалыгы “Яңа Иерусалим” буларак тасвирлана. Ул бик тә, бик тә зур, тыштан биек дивары бар. Дивар бәллүр кебек үтәкүренмәле яшма ташыннан эшләнгән. Дивар нигезен, ялтыр-йолтыр килеп, кыйммәтле асылташлар каплап тора. Кала капкаларының барысы да зур бер энҗе бөртегеннән ясалган!



8

Энҗе бөртегеннән ясалган әлеге зур капкалар беркайчан да ябылмый. Әйдәгез, эченә үтеп керик, як-якка караныйк... Ә анда! Эчке ягында ул тагын да зиннәтлерәк. Шәһәр пыяла кебек үтәкүренмәле пакъ алтыннан корылган. Хәтта урамы да алтыннан.



9

Аллаһы тәхетеннән бәллүр сыман ялтырап торган тереклек суы ага. Елганың бу һәм теге як ярында элек Гадән бакчасында үскән Тереклек Агачы бар. Бу бик үзенчәлекле агач. Һәр айны берәр төр җимеш биреп, ул унике төрле җимеш бирә. Ә агачның яфраклары халыкларны савыктыру өчен билгеләнгән.



10

Күкләр Патшалыгы кояшның һәм айның яктыртуына мохтаҗ түгел, чөнки аны Аллаһының даны яктырта. Анда беркайчан да төн җитми.



11

Күкләрдәге хайваннар да бөтенләй башка. Алар кулга ияләштерелгән һәм дус. Бүреләр белән бәрәннәр бергәләшеп үлән ашый. Хәтта әзмәвер арысланнар да үгез кебек салам белән туклана. Аллаһы Тәгалә әйтә: “Алар Минем Изге тавымда явызлык вә яманлык кылмаячак”, - ди.



12

Әйләнә-тирәбезгә күз салсак, Күкләрдә булмаган әйберләр булуын күреп алырбыз. Бер генә яман сүз дә ишетелмәс. Беркем дә көрәшмәс, үзен-үзе генә яратып яшәмәс.



Ишекләр йозаксыз, чөнки анда караклар юк. Монда ялганчылар, кеше үтерүчеләр яки башка явыз бәндәләр дә булмас. Күкләр Патшалыгында һичбер гөнаһ юк.

13



Күкләрдә, Аллаһы янәшәсендә беркайчан да күз яше түгелмәс. Вакыты-вакыты белән Аллаһы бәндәләре бу тормыштагы бөек кайгылары турында гына елар. Күкләрдә Аллаһы барлык күз яшен дә киптерер.

14

Күкләрдә үлем дә юк. Аллаһы бәндәләре һәрчак Раббылары янәшәсендә булыр. Кайгы күрмәс, күз яше түкмәс, авырту тоймас. Авырулар да, аерылышулар да, җирләүләр дә булмас. Күкләрдә барысы да Раббылары белән мәңге бәхетле булыр.





Ә иң мөһиме – Күкләр Патшалыгы Гайсә Мәсихкә үзләрен Коткаручы буларак иман китергән һәм Раббысы кебек аңа буйсынган малайлар һәм кызлар өчен (өлкәннәр өчен дә) билгеләнгән. Күкләрдә «Бәрәннең Тормыш китабы» дип аталган китап булыр. Анда кешеләрнең исемнәре язылган. Анда кемнәрнең исемнәре язылган булуы турында беләсезме? Гайсәгә иман китергән кешеләрнең исемнәре язылган анда.




Ә синең исемең бармы анда?



Изге Язмада Күкләр турындагы соңгы сүзләр – могҗизалы чакыру ул. – Рух та, кәләш тә “Кил!” - диләр. Һәм ишетүче дә: “Кил!” - дип әйтсен. Сусаучы килсен, теләгән кеше тереклек суын бушлай алсын.






Оҗмах, гүзәл Аллаһы йорты

Аллаһы Сүзеннән, Изге Язмадан хикәят

урнашкан

Яхъя 14, II Көринтлеләргә хат 5;
Ачылыш 4, 21, 22

“Сүзләреңнең күренүе балаларны яктыртып акыллыландыра.” Мәдхия 119:130






60 60



Әлеге Изге Язма хикәятендә Җир йөзендәге барча тереклекне бар кылган һәм Үзенә иман китерүебезне теләгән кодрәтле Аллаһы турында бәян ителә.

Раббыбыз начар гамәлләр кылуыбыз турында белеп тора, Ул аларны гөнаһ дип атый. Гөнаһның җәзасы – үлем. Ләкин Аллаһы сезне шулкадәр ярата ки, гөнаһларыгыз өчен җәзаланырга дип бердәнбер Улы Гайсәне хачта үтертү өчен җибәрде. Шуннан соң Гайсә үлеп терелде һәм Күккә ашты! Гайсәгә ышансагыз, гөнаһларыгызны кичерүе турында сорагыз, Ул моны эшләр! Ул килер һәм сездә яшәр, һәм сез дә мәңге Аның белән бергә булырсыз.

Моның хак булуына ышансагыз, Аллаһыга болай диегез: Хөрмәтле Гайсә, Синең Раббы булуыңа һәм гөнаһларым хакына һәлак ителү өчен кеше булып яралтылуыңа һәм хәзерге вакытта исән булуыңа ышанамын. Зинһар өчен, тормышыма үтеп кер, мин яңа тормыш башлап, кайчан да булса Синең белән мәңге бергә була алсын өчен, гөнаһларымны ярлыка. Балаң күк, Сиңа сәҗдә кылып, Сиңа иман китереп яшәргә ярдәм ит. Амин.

Изге Язма укы һәм көн саен Аллаһы юлында бул! (Яхъя 3:16)